**Рәшит БӘШӘР,**
*язучы, 2000-2007 елларда «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе*

# ШИФАЛЫ ТАМЧЫЛАР ҖЫЛЫСЫ

...Җитмешенче еллар башы... Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган яшь шагыйрь Хәниф Хөснуллин Чаллы якларына эшкә тәгаенләнә. Биклән мәктәбендә балалар укытып йөргән егет Чаллыда әдәбият түгәрәге оештырып җибәрә. Түгәрәккә Түбән Кама районы Ташлык авылыннан Разил Вәлиев, Зәй районы Биш Субашыннан Мөдәррис Әгъләмов та тартыла.

Кама буендагы автогигант төзелеше тәвәккәл иҗат яшьләрен үзенә тарта. «Коммунизм байрагы» редакциясе каршында оешкан иҗат түгәрәге һәр сәләтле каләм иясен үз яктысына җыя.

Җилләр исте, комнар күчте... Кыяр-кыймас кына «Ләйсән» ишеген шакыган егетләр татарның күренекле язучылары булып үсеп җитте. Мөдәррис Әгъләмов – Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Разил Вәлиев күренекле каләм остасы (Муса Җәлил премиясе лауреаты) булу белән бергә талантлы сәясәтче дә булып танылды. Тарихи романнар авторы Вахит Имамов, шагыйрь һәм прозаик Факил Сафин Гаяз Исхакый исемендәге премиягә лаек булдылар.

Чаллыда әдәби хәрәкәтнең беркайчан да сүнеп торганы булмады. Чаллы Язучылар оешмасы әдәби алмаш тәрбияләү юнәлешендә нәтиҗәле эш алып бара. «Ләйсән»гә милли рухлы яшьләр килә.

Иксез-чиксез дәрьяда шаулаган кылганнар гасыр катламнарыннан халкыбызның ireккә сусаган авазын җиткерә, Идел-Чулман ярларына ярсулы дулкыннар сугыла…

Кылганнарга, дулкыннарга язның беренче шифалы тамчылары тама…

Ләйсәннәр...

*Ләйсән тамчылары: Чаллы язучылар берләшмәсе каршында эшләп килүче «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе альманахы / Төз.: Р. Хәмидуллина. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе, 2007. – Б.3-4.*